**Дәреснең технологик картасы**

**Укытучы -** Халитова Л.А.
**Предмет:** татар теле
**Программа:** Татарстан Республикасы Мәгариф һәм Фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән “Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы” (рус телендә сөйләшүче балалар өчен) 1-11 нче сыйныфлар өчен, К.С.Фәтхуллова, Ф.Х.Җәүһәрова, - Казан; Мәгариф; 2010.
**Дәреслек:**

**Бүлек темасы**:
**Дәрес темасы:** Сыйфатны кабатлау
**Дәреснең максаты, бурычлары:**
1) Алмашлык сүз төркемен ныгыту.
**2)** Яңа лексиканы сөйләмдә урынлы куллана белү, тема буенча фикерне җиткерә белү. Фикерләрне логик чылбырга салу, әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү.
**3)** Табигатьнең матурлыгын күрә белергә өйрәнү, табигать белән хозурлана белү, аралашу теләге уяту.
**Дәрес төре:** кабатлау, ЛГКФ
**Җиһазлау:** рәсемнәр, интеркактив такта, карточкалар

**Дәрес барышы**

| Дәрес этаплары | Укытучы эшчәнлеге | Укучылар эшчәнлеге | |
|---|---|---|---|
| **I. Оештыру өлеше**<br>**Этапның максаты:**<br>- Укучыларны дәрескә һәм яңа | - Исәнмесез, укучылар!<br>- ...<br>- Хәерле көн!<br>- ...<br>Укучылар, минем исемем Лилия | **Шәхси УУГ** | - Бер – береңне хөрмәт итү; укуга карата кызыксыну хисе булу, укучы ролен үзләштерү |

| Дәрес этаплары | Укытучы эшчәнлеге | Укучылар эшчәнлеге | |
|---|---|---|---|
| белемнәр алуга әзерләү.<br>- Укучыларны уку процессына кереп китү мотивациясе өчен шартлар тудыру. | Азатовна. ("Хәерле көн телим "шигыре.)<br>**Һәр көн саен хәерле көн телим,**<br>**Аяз күкләр телим җиремә.**<br>**Биек күкләр телим бөркетләргә**<br>**Һәм иминлек телим илемә.**<br>**Юлчыларга хәерле көн телим,**<br>**Чәчкәләргә карап елмаям.**<br>**Һәрбер кеше якын кардәш сыман,**<br>**Үз балам күк тоела һәр бала.** | **Танып белү УУГ** | - Сәнгатьле һәм йөгерек уку күнекмәләре булдыру; сөйләм телен үстерү. |
| | - Мин сезгә үземнең укучыларымнан, яшьтәшләрегездән сәлам алып килдем. Әйдәгез шуны карыйк әле. (видеода 170 нче мәктәпнең укучылары мөрәҗәгате)<br><br>-. Ә хәзер игътибар экранга. Әйдәгез әле искә төшереп үтик. Сез нинди сүз төркемнәрен беләсез? (исем, сыйфат, сан, алмашлык, фигыль, рәвеш, аваз ияртемнәре).<br>- Телеграмма килеп төште. Минем абыемнан. Әйдәгез әле аңа күз салыйк. (Телеграмма. Хәерле көн укучылар! **Сезгә** кайнар сәламнәремне җиткерәм. **Мин** | **Коммуникатив УУГ** | - Сөйләм этикеты нормаларын үтәү: исәнләшә, саубуллаша, рәхмәт белдерә белү.<br>- Башкаларның сөйләмен тыңлый һәм аңлый белү. |

| Дәрес этаплары | Укытучы эшчәнлеге | Укучылар эшчәнлеге | |
|---|---|---|---|
| **II. Белемнәрне актуальләштерү**<br>**Этапның максаты:** | бүген балыкка бардым. Һава торышы искиткеч! **Минем** белән якын дустым Акбай да бар иде. **Ул** уңышларыма бик сөенде. Тиздән **сезгә** кунакка киләм.<br>- Балалар, әлеге телеграммада , сезнең уйлавыгызча, нәрсә җитми. Шуларны өстәп языгыз. Алар нинди сүз төркеменә карый? Димәк без сезнең белән нинди сүз төркеме турында сөйләшәчәкбез? (Алмашлыклар)<br>- Аламашлыклар безгә ни өчен кирәк (Текстны тулылрак итәр өчен, текстта кабатлаулар булмас өчен). Ә хәзер әйдәгез алмашлыклар буенча алган белемнәрегезне тикшереп карыйк. Мин сорау бирәм, ә сез кул күтәреп җавап бирерсез.<br>Алмашлыклар ни өчен кирәк? Мәгънәләре ягыннан алмашлыклар нинди төркемчәләргә бүленә? Аларны атап китегез. Ясалышлары ягыннан алмашлыклар ничә төркемчәгә бүленә? Нинди җөмлә кисәге булып килә алалар?Алмашлыклар сөйләмдә нинди әһәмияткә ия? (Җаваплар: 1.Исемне, сыйфатны, сан һәм рәвешне алмаштырып килә | | |

| Дәрес этаплары | Укытучы эшчәнлеге | Укучылар эшчәнлеге | |
|---|---|---|---|
| | торган мөстәкыйль сүз төркеме. алмашлык дип атала. 2.Җиде төркемчәгә бүленә: зат, тартым, күрсәтү, сорау. Билгеләү, билгесезлек, юклык алмашлыклары. 3. Тамыр, кушма, парлы, тезмә, ясалма алмашлыклар була. 4. Ия, хәбәр, аергыч, тәмамлык булып килергә мөмкин. 5. Алмашлыклар сөйләмне җыйнак һәм матур яңгырашлы итә. Урынсызга бер үк сүзне кабатлаудан коткаралар. | | |
| - III. **Укучыларның белемнәрен ныгыту**<br>-Балаларның тормыш тәҗрибәсенә якын булган | Ә хәзер алган белемнәрегезне тагын бер кат искә төшерү өчен һәм группаларга бүленер өчен конверттагы биремнәрне үтәп | **Шәхси УУГ** | -Булган белемнәрне активлаштыру.<br>-Тема буенча актив эшләү. |

| Дәрес этаплары | Укытучы эшчәнлеге | Укучылар эшчәнлеге | |
|---|---|---|---|
| биремнәр бирү.<br>- үзләштергән белемнәрне гамәлдә куллану. | алыйк. һәрбер балага конверт бирелә. Конвертта алмашлык кергән җөмлә бирелгән. Шул алмашлыкның нинди төркемчәгә караганын белеп, сез группаларга бүленергә тиеш булачаксыз.<br>(Зат алмашлыклары, күрсәтү алмашлыклары, сорау алмашлыклары). Һәрберсенә үзегезнең мисалыгызны да әйтеп китегез. Ә хәзер кем нинди төркемдә булуына карап, шул өстәл янына утырасыз.<br>Телеграммада күренгәнчә, абыем балык тотарга бик ярата икән. Көннең нинди булуына карап, балыклар төрлечә эләгә. Бүген тыныч, аяз. Абыема балыклар күп эләккән. Әйдәгез без ул балыкларны урнаштырыйк әле.<br>Интерактив тактада балыклар бирелгән алар нинди затка карый, шул чиләккә куярга кирәк булачак.<br>Бик шәп!<br>Ә балык эләкмәгән вакытта моңсуланмас өчен абыем җырлап җибәрергә ярата. (һәр командага җыр яңгырый, аларда алмаш-ны табарга кирәк булачак.)<br>Балыклар күп эләкте. Ләкин араларында бик кечкенә балыклар | **Танып белү УУГ** | - Укытучының сорауларын тыңлау.<br>- Укытучы сорауларына җавап бирү.<br>- Шәхси тормыш тәҗрибәсен актуальләштерүне тормышка ашыру.<br>- Билгеләре буенча гомумиләштерү һәм классификация ясауны формалаштыру. |
| | | **Коммуникатив УУГ** | -Дәрестә һәм төрле ситуацияләрдә диалогта катнаша белү.<br>-Укытучының сорауларына җавап бирү.<br>-Башкаларның сөйләмен тыңлый һәм аңлый белү. |
| | | **Коммуникатив УУГ** | - Әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый белүне, укытучы һәм сыйныфташларың белән бергә эшли белүне формалаштыру. |

| Дәрес этаплары | Укытучы эшчәнлеге | Укучылар эшчәнлеге | |
|---|---|---|---|
| | да бар.Әйдәгез әле аларны аралыйк. Мондый биремне үтәп, без алга таба эшебезне дәвам итәрбез.<br>“Кайсы артык” уены.<br>1) Мин,син, нәрсә,без<br>2) Сез, бу,теге, шул<br>3) Кем,нәрсә? кайсы?һичкем<br>4) Һичкайда,һичбер, алар,һичнәрсә<br>Нәрсәдән чыгып сез әлеге алмашлыкларны төшереп калдырдыгыз? | | |
| | | | |
| **VI. Материал белән практик эш**<br>**Этапның максаты:**<br>- үзконтроль, бер-береңә карата контроль һәм үзбилгелүгә өйрәтү;<br>- ситуатив күнегүне оештыру;<br>- ясаган хаталарны төзәтүне оештыру. | Абыйны шатландырыр без сезнең белән дәреснең схемасын ясарга тиеш булабыз. Ул схеманың төп сүзе буларак кайсы сүз төркемен алырга була. Ягъни безбүген нәрсә турында сөйләштек?<br>Дәрескә нинди уку мәсьәләсе куелды? Аны ничек чиштек? | **Шәхси УУГ** | - материалны кабатлау һәм практикада куллана белү.<br>- Алган белемнәр буенча фикерләрне тулыландыру, ачыклау.<br>- 3) Табигатьнең матурлыгын күрә белү. |

| Дәрес этаплары | Укытучы эшчәнлеге | Укучылар эшчәнлеге | |
|---|---|---|---|
| | | **Регулятив УУГ** | - Фикерләрне логик чылбырга салу,<br>- әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү,<br>- күршең белән хезмәттәшлек итү<br>- ясаган хаталарны төзәтүне оештыру. |
| | | **Танып белү УУГ** | - Белемнәрне структуралаштыра белү.<br>- Биремнәрне үтәүнең уңайлы чараларын табу.<br>- Логик фикерләүне үстерү |
| **VII. Рефлексия. Өй эше бирү.** | Йомгаклау эше.<br>- Сез бүгенге дәрестән нәрсә истә калдырдыгыз?<br>- Без бүген нәрсә турында сөйләштек?<br>- (укучыларның җавапларын тыңлау)<br>Бүген алган белемнәребез киләчәктә дөрес кулланырсыз дип ышанып калам. Тормышта сөйләмебез матур булсын өчен сыйфатларны ешрак кулланыйк.<br>Абый безгә көчтәнәч итеп төрле | **Танып белү УУГ** | |

| Дәрес этаплары | Укытучы эшчәнлеге | Укучылар эшчәнлеге | |
|---|---|---|---|
| | төстәге балыклар җибәргән.Кызыл, яшел, зәңгәр. Киткәндә сез аларны аквариумга ябыштып китәрсез.<br>1) Өй эше бирү<br>2) Дәрестә катнашкан укучылар эшчәнлегенә бәя бирү. | | |